ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с. Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**« 29 » сентябрь 2016 ел** **№ 23**

**«Арча муниципаль районының Сеҗе авыл җирлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентында җирле әһәмияттәге юллар буйлап тулысынча яисә өлешчә уза торган маршрутлар буенча автомобиль йөртүгә, эре габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 18 июлендәге 19 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар буйлап тулысынча яисә өлешчә уза торган маршрутлар буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын раслау хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе Салым кодексының 2000 елның 5 августындагы 117-ФЗ номерлы 333.33 маддәсенең 1 пунктындагы 111 пунктчасы, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 18 июлендәге 19 номерлы карары нигезендә Сеҗе авыл җирлегенең башкарма комитеты карар бирде:

1. Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 18 июлендәге 19 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар буйлап тулысынча яисә өлешчә уза торган маршрутлар буенча автомобиль йөртүгә, эре габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына «Сеҗе авыл җирлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Сеҗе авыл җирлеге карары белән расланган муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә уза торган маршрутлар буенча рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 бүлекнең 2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт пошлинасы күләмнәре: автомобиль юлы буйлап йөртүне гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт биргән өчен (халыкара автомобиль ташуларны гамәлгә ашыручы транспорт чарасыннан тыш): куркыныч йөкләр - 1300 сум; авыр йөк һәм (яисә) эре габаритлы йөкләр - 1 600 сум | РФ НК 333.33 статьясының 1 пунктындагы 111 пунктчасы |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Гибадуллина Г.М.